**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОИГЛАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНА ИГЛАЙ АВЫЛЫНЫН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**КАРАР** Яңа Иглай ав. **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

20.11.2025 ел № 29

Яңа Иглай авыл җирлеге башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 25 мартындагы 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Яңа Иглай авыл җирлеге Башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 25 мартындагы 5 номерлы карарына (2024 елның 18 июнендәге 8 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 статьясының 2.5.1 пунктының 4 пунктчасын «2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, шулай ук муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеген, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысулларын, шул исәптән электрон рәвештә, тапшыру тәртибе» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк булган очракта һәм федераль закон нигезендә мондый шәхси күрсәткечләрне эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булган очракта, муниципаль хезмәтне алу өчен мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртүгә ризалыгын алуын раслый торган өстәмә документлар тапшыра. Ризалык алуны раслый торган документлар шул исәптән электрон документ рәвешендә дә тапшырылырга мөмкин.».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче М.И. Хәмидуллин